# КАРАР

## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлегенең Кече Кибәхуҗа торак пунктында гражданнар җыены буенча

**2019 елның 23 ноябре** **№ 2** **Кече Кибәхуҗа авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,2019 елның 23 ноябрендә Кече Кибәхуҗа торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде,, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлегенең Кече Кибәхуҗа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

1) Кече урамы буенча балалар уен мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

2) Урам утлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү.

3) Кече урамы буенча вак таш җәелгән юлларны ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, эш өчен түләү).

4) Мәгълүмат стенды алу.

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 47 кеше кертелгән;

җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 31 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

гражданнар җыенында 31 катнашучы «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлегенең Кече Кибәхуҗа авылында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлегенең Кече Кибәхуҗа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

1) Кече урамы буенча балалар уен мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

2) Урам утлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү.

3) Кече урам буенча вак таш җәелгән юлларны ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, эш өчен түләү).

4) Мәгълүмат стенды алу.

- кабул ителгән.

3. Гамәлдәге законнар нигезендә гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында әлеге карарны игълан итәргә, шул исәптән мәгълүмат стендларында һәм Кече Кибәхуҗа авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Башлыгы: И. [illegible]. Заһидуллин